ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын даими нигездә биләүче затларга Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән өстәмә социаль гарантияләр һәм башка гарантияләр билгеләнергә мөмкин.»;

2) 15 статьяда:

а) $2^1$ өлештә «2 өлеше нигезендә» сүзләрен «2 яисә $2^2$ өлеше нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^2$ өлеш өстәргә:

«$2^2$. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләгән затка пенсиягә өстәмә, аның бер Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы буенча кимендә биш ел стажы (вазыйфада булуның бер тулы срогы) булмаса, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасында булу срогы кимендә ике ел да алты ай тәшкил итә торган мондый вазыйфа буенча билгеләнә. Бу чакта пенсиягә өстәмә айлык акчалата гомуми исәпләнгән хезмәт хакының 35 проценты күләмендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән, әлеге өлешнең беренче абзацы нигезендә пенсиягә өстәмә алу хокукына ия булган затларга пенсиягә өстәмә күләме бу Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын яисә башка Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын даими нигездә ике ел да алты айдан артыграк биләүнең һәр ае өчен 1 процентка арттырыла. Бу чакта пенсиягә өстәмә күләме пенсиягә өстәмәне билгеләү датасына айлык акчалата гомуми исәпләнгән хезмәт хакының 70 процентыннан артмаска тиеш.».

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 өлешнең 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 11 өлештә «10 өлешендәге 1 – 3 пунктларында» сүзләрен «10 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 2 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 44 (I өлеш), № 76 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән пенсиягә өстәмәләрнең күләме, әлеге Закон нигезләмәләрен исәпкә алып, ул үз көченә кергән көннән башлап яңадан исәпләнергә тиеш. Әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмәне яңадан исәпләгәндә, аның күләме элегрәк билгеләнгәне белән чагыштырганда кимегән очракта, пенсиягә өстәмә элеккеге күләмдә түләнә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 12 декабрь
№ 92-ТРЗ